КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 март г.Казань № 140

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 3 ноябрь, 979 нчы; 2018 ел, 21 декабрь, 1200 нче; 2018 ел, 28 декабрь, 1252 нче; 2019 ел, 12 февраль, 98 нче; 2019 ел, 24 май, 438 нче; 2019 ел, 9 июль, 559 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 849 нчы; 2019 ел, 16 декабрь, 1151 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1213 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1215 нче; 2020 ел, 24 февраль, 139 нчы; 2020 ел, 27 июнь, 537 нче; 2020 ел, 10 ноябрь, 1008 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Җәнлек үрчетү хуҗалыкларына читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = S \times 80\%,$$

монда:

S – агымдагы елда терлек азыгы, азык өстәмәләре, ветеринария медикаментлары, биопрепаратлар һәм дезинфекция препаратларын сатып алуга тотылган чыгымнарның (өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнар тотып калынган) суммасы, сум.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6. Субсидияләр алу өчен алучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча язылган, түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүмат булган субсидия бирү турында гариза:

субсидия алучының законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлүе һәм җитештерү эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыруы;

субсидия алучы – юридик затның үзгәртеп оештыру процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы, ә субсидия алучы – индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавы;

алучының чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 процenttан артып киткән Россия юридик заты булмавы;

субсидия алучының әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавы;

алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы;

алучының салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавы;

Россия Федерациясенең Статистика буенча дәүләт комитеты тарафыннан расланган форма буенча үткән финанс елының декабре өчен хайваннарның хәрәкәт итүе турында хуҗалык эчендәге хисап күчермәсе;

үткән финанс елы өчен рәсми статистика хисабы төзелгән терлекчелек торышы турында мәгълүмат;

җәнлек үрчетү хуҗалыгы җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган агымдагы елның 1 февраленә бухгалтерлык хисаплылыгы нигезендә төп терлекнең ана баш саны аерып күрсәтелгән җәнлекләрнең төрләр буенча баш саны турында мәгълүматлар;

терлек азыгы, азык өстәмәләре, биопрепаратлар, ветеринария медикаментлары, дезинфекция препаратлары сатып алуга шартнамәләрнең күчермәләре;

терлек азыгы, азык өстәмәләре, биопрепаратлар, ветеринария медикаментлары, дезинфекция препаратлары сатып алуга йөкнамәләрнең күчермәләре;

терлек азыгы, азык өстәмәләре, биопрепаратлар, ветеринария медикаментлары, дезинфекция препаратлары сатып алуга түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмә кәгазе.

Субсидияләр алучылар үз инициативасы белән алучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазен тапшырырга хокуклы. Әгәр дә әлеге документ субсидия алучы тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаса, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидияләр алучылар тарафыннан раслана.»;

10 пунктның беренче абзацында «алучыларның исәп-хисап счетларына» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучылар өчен ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар чыгымнарының бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта:

беренче абзацта «һәм (яки) хисап финанс елы белән чагыштырганда агымдагы финанс елында чәчүлек мәйданнарын арттырган» сүзләрен төшереп калдырырга, «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә, «өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча» сүзләрен «өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнары тотып калынган» сүзләренә алмаштырырга;

«а» пунктчада «авыл хуҗалыгы культуралары үсә торган» сүзләре алдына « агымдагы елда, хисап елы белән чагыштырганда, арттыру шарты белән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм арттыру максаты белән хисап финанс елында туфрак мелиорантларын (Россия Федерациясе территориясендә кулланырга рөхсәт ителгән Дәүләт пестицидлар һәм агрохимикатлар каталогына кертелгән фосфорит оны, известь оны, доломит оны, мергель, дефекацияле известь, авыл хуҗалыгы өчен фосфогипс) сатып алу, транспортлау һәм кертү (алга таба – мелиорантлар сатып алу, транспортлау һәм кертү).»;

3 пунктта:

икенче абзацта җөмлә башына «субсидия алучылар тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен:

субсидия алучы тарафыннан хисап елында мелиорантларны кертү буенча эшләр башкару;

2022 елдан башлап, Министрлык боерыгы белән раслана торган хисап елында Мелиорантларны кертү чараларын цифрлаштыру буенча тәкъдимнамәләрне үтәү.»;

4 пунктта:

икенче абзацта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «бетерү» сүзе алдына «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Үсемлекчелек өлкәсендә ярдәм күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:»;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унберенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

уникенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «алучыларга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ябык грунттагы яшелчәләрне стимуллаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{зг}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{зг} = П_{зг} \times S_{зг},$$

монда:

$П_{зг}$ – субсидия алучының хисап финанс елында булган ябык грунт яшелчә культуралары биләгән мәйдан, квадрат метр;

$S_{зг}$ – ябык грунттагы яшелчәләрне стимуллаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия ставкасы, 1 квадрат метрга 30,0 сум исәбеннән.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Чәчүлекләргә фитосанитар тикшерү үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_ф$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_ф = П_ф \times S_а,$$

монда:

$П_ф$ – субсидия алучыда булган, агымдагы финанс елында фитосанитар тикшерү үткәрелгән чәчүлекләр мәйданы, гектар;

$S_ф$ – чәчүлекләргә фитосанитар тикшерү үткәрү өчен 1 гектарга 150,0 сум исәбеннән субсидия ставкасы.»;

$7^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$7^1$. Агымдагы финанс елында куллану шарты белән минераль ашламалар активаторларын сынауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия

алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{ак}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{ак} = Z_{ак} \times 95\%,$$

монда:

$Z_{ак}$ – субсидия алучының алга таба сынау өчен һәм агымдагы финанс елында куллану шарты белән минераль ашламалар активаторларын сатып алуга бәйле булган һәм өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнары һәм транспорт чыгымнары тотып калынган чыгымнары, сум.

Субсидия күләме субсидия алучының авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренең 1 гектарына 3 000,0 сумнан арта алмый.»;

түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

«$7^2$. Хисап финанс елында мелиорантлар сатып алуга, транспортлауга һәм кертүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{мел}$) (сум) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{мел} = R_{з} \times \frac{55}{100},$$

монда:

$R_{з}$ – субсидия алучының хисап финанс елында мелиорантлар сатып алуга, транспортлауга һәм кертүгә бәйле булган һәм өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнары тотып калынган чыгымнары.»;

8 пунктта:

беренче абзацта «$7^1$» саннарын «$7^2$» саннарына алмаштырырга, «алучылар» сүзе алдына «субсидияләр» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бетерү» сүзе алдына «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унынчы абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

9 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

икенче абзацта «алучыда» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «алучыда» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен субсидия алучылар Идарәгә өстәмә рәвештә хисап финанс елында үсемлекчелек продукциясен җитештерү, аларның чыгымнары, үзкыйммәте һәм аларны реализацияләү турында хисап һәм (яки) хисап елы өчен крестьян (фермер) хуҗалыклары – индивидуаль эшмәкәрләр башлыкларының җитештерү эшчәнлеге турында мәгълүмат тапшыра.»;

11 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

$11^{1}$ пунктның беренче абзацында «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $11^{2}$ пункт өстәргә:

«$11^{2}$. Әлеге Тәртипнең $7^{2}$ пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен субсидия алучылар Идарәгә өстәмә рәвештә, өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнары тотып калып, хисап финанс елында мелиорантларны сатып алу, транспортлау һәм кертү чыгымнарын раслый торган документларны (сатып алу-сату шартнамәләре күчермәләрен, чит оешмаларны җәлеп иткәндә эшләр башкаруга подряд шартнамәсе күчермәләрен, товар йөкнамәләре күчермәләрен, башкарылган эшләр актлары күчермәләрен, түләү йөкләмәләрен, счет-фактураларны, хуҗалык эчендәге документларны, минераль, органик һәм бактериаль ашламаларны файдалану турында актлар күчермәләрен (420-АПК номерлы формасы) тапшыра.»;

12 пунктта:

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән чаралар буенча – хисап елында мелиорантлар кертү чаралары гамәлгә ашырылган сөрү җирләре мәйданы, гектар.»;

$14^{1}$ пунктта «1 сентябренә» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Министрлык әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм Идарәләр тарафыннан субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисаплар белешмә кәгазьләре кертелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына караган Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисаплар белешмә кәгазьләре субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора. Идарәләр бюджет акчасы үз шәхси счетына кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучылар өчен ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

16 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

17 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзе алмаштырырга;

18 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзе алмаштырырга; «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

19 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада «1 сентябренә кадәр» сүзләрен «31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «(фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «(Ф.И.Ат.ис (соңгысы – булганда))» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта:

унсигезенче абзацта «(алга таба – техника)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елдан да иртәрәк сатып алынмаган, парлы яки киң көпчәкле тәгәрмәчләр белән комплектланган, егәрлеге 200 ат көченнән артык булган тракторлар (алга таба – техника).»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Алучыларга субсидия түбәндәге күләмдә бирелә:

а) өстәлгән бәягә салымны, монтажны, транспорт һәм башка хезмәт күрсәтүләрне исәпкә алмыйча, кайтарту (сатып алу-сату) шартнамәләре буенча сатып алынган техниканың (үзйөрешле сиптергечләрдән тыш) фактагы чыгымнарыннан 30 процент, әмма иң күбе:

бер тракторга 6,0 млн.сум;

бер ашлык җыю комбайнына, үзйөрешле азык җыю комбайнына, үзйөрешле яшелчә комбайнына яки үзйөрешле ургычка (чапкычка) 7,0 млн.сум;

бер үзйөрешле бәрәңге җыю комбайнына 10,0 млн.сум;

бер үзйөрешле чөгендер җыю комбайнына 12,0 млн.сум;

б) хисап финанс елына кадәрге елда, хисап һәм агымдагы финанс елларында башкарылган, өстәлгән бәягә салымны, монтажны, транспорт һәм башка хезмәт күрсәтүләрне исәпкә алмыйча, фактта түләнгән лизинг түләүләреннән 30 процент;

в) өстәлгән бәягә салымны, монтажны, транспорт һәм башка хезмәт күрсәтүләрне исәпкә алмыйча, кайтарту (сатып алу-сату) шартнамәләре буенча сатып алынган үзйөрешле сиптергечнең фактагы чыгымнарыннан 50 процент, әмма иң күбе:

бер үзйөрешле сиптергечкә 4,0 млн.сум.»;

7 пунктның беренче абзацында «5 пунктның «а» пунктчасында» сүзләрен «5 пунктның «а» һәм «в» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта:

беренче абзацта «алучыларның исәп-хисап счетларына» сүзләрен «Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучылар өчен ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «алучыларның исәп-хисап счетларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Минераль ашламалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә, «(өстәлгән бәягә салымны исәпкә алмыйча)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктта:

өченче абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә, «35» саннарын «40» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«файдаланыла торган сөрү җирләренә агрохимик тикшерү үткәрүнең бишьеллык циклын үтәү;

2022 елдан башлап, Министрлык боерыгы белән раслана торган Файдаланыла торган сөрү җирләре турындагы мәгълүматларны цифрлаштыру буенча тәкъдимнамәләрне үтәү.»;

4 пунктта:

беренче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

икенче абзацта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «бетерү» сүзе алдына «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

икенче абзацта «$W = П \times 515{,}0 + W_{сем.}$ I кат. + $W_{сем.}$ II кат.» сүзләрен «$W = П \times 400{,}0 \times 1{,}3 + W_{сем.}$ I кат. + $W_{сем.}$ II кат.» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

бишенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«1,3 – субсидия алучының Министрлык боерыгы белән раслана торган Измәдән эшләнгән комплексларны төзү буенча тәкъдимнамәләргә җавап бирә торган измәдән эшләнгән комплексы булганда кулланыла торган коэффициент;»;

җиденче абзацта «алучыларга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «алучыларга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

тугызынчы абзацта «алучыларга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

уникенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «алучыларга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унҗиденче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унтугызынчы абзацта «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

7 пунктта:

беренче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

өченче абзацта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бетерү» сүзе алдына «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

җиденче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

тугызынчы абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә, «35» саннарын «40» саннарына алмаштырырга;

унынчы абзацта «алучы» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

уникенче абзацта «алучының» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«субсидия алучы тарафыннан таныкланган һәм «Татарстан» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе яки «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) белән килештерелгән файдаланыла торган сөрү җиренә агрохимик тикшерү үткәрүнең бишьеллык циклын үтәү турында ирекле рәвештә язылган мәгълүмат, гектар;

субсидия алучы тарафыннан таныкланган һәм «Татарстан» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе яки «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) белән килештерелгән Министрлык боерыгы белән раслана торган форма буенча измәдән эшләнгән комплексларны тикшерү акты (субсидия күләмен исәпләп чыгарганда измәдән эшләнгән комплексларга арттыру коэффициентын кулланганда).»;

8 пунктта:

бишенче абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

алтынчы абзацта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

унөченче абзацта «алучыга» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле «и» абзацы өстәргә:

«и) субсидия алучының хисап бирү һәм алга таба кертү өчен минераль ашламаларны субсидия алганнан соңгы чорда өстәлгән бәягә салым түләү чыгымнарын исәпкә алып күчерелгән субсидия суммасыннан ким булмаган суммага сатып алу турындагы раслый торган документларны тапшыру хакында йөкләмәсе»;

10 пунктта «кертү» сүзен «алга таба кертү өчен сатып алу» сүзләренә алмаштырырга, «45» саннарын «8» санына алмаштырырга;

$10^1$ пунктта «1 сентябренә» сүзләрен «31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм Идарәләр тарафыннан субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисаплар белешмә кәгазьләре кертелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган үз шәхси счетыннан Идарәләрнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына караган Казначылык департаментының территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

Идарәләр тарафыннан Министрлыкка кертелгән субсидия алучылар яктылыгында бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисаплар белешмә кәгазьләре субсидияләрне күчерү өчен нигез булып тора. Идарәләр бюджет акчасы үз шәхси счетына кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидияләрне Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучылар өчен ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.»;

12 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

14 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга;

15 пунктта «законнар» сүзе алдына «Россия Федерациясе» сүзләрен өстәргә, «законнар» сүзен «законнары» сүзенә алмаштырырга; «алучыларның» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

16 пунктта «алучылар» сүзе алдына «субсидия» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада «1 сентябренә кадәр» сүзләрен «31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «(фамилиясе, исеме, атасының исеме)» сүзләрен «(Ф.И.Ат.ис (соңгысы – булганда))» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин